**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Комыргуҗа авыл җирлеге Мәрҗән торак пунктында**

## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

"21" ноябрь 2021 ел. № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-Фз номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлегенең Мәрҗән торак пунктында халык җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Мәрҗән авылы территориясендә 2022 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлегенең Мәрҗән авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

-Мәрҗән авылы зиратын чистарту өчен чыгымнар тоту;
-Мәрҗән авылы клубын койма белән әйләндереп алу;
-Мәрҗән авылындагы чишмә әйләнәсен төзекләндерү өчен чыгымнар тоту;
-Мәрҗән авылын чистарту,төзекләндерү өчен чыгымнар тоту.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлегенең Мәрҗән авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Комыргуҗа авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4 Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Мәрҗән авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Комыргуҗа авыл җирлеге башлыгы Низамиев Ф.Ф.